ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

## 1 статья

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

“9) пассажирлар йөртүне, багаж, йөкләр, почта ташуны түләүле гамәлгә ашыра торган авиация предприятиеләренә – һава суднолары (җиңел һәм аеруча җиңел һава судноларыннан тыш) һәм авиация двигательләренә карата.”;

2) 5 статьяда:

а) 2 пунктта “2016 елның 1 гыйнварыннан” сүзләрен “2019 елның 1 гыйнварыннан” сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 пунктта “2 өлешенең 5, 8 пунктларын” сүзләрен “2 өлешенең 5, 8, 9 пунктларын” сүзләренә алмаштырырга.

## 2 статья

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. “Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 9 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) әлеге Закон үз көченә кергәннән соң Татарстан Республикасында төзелгән йә урнашу урынын беренче тапкыр Татарстан Республикасы территориясенә алмаштырган авиация предприятиеләренә карата кулланыла.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 12 июне
№ 38-ТРЗ